
***Бергәләп өйрәник***



***Өлкәннәргә хөрмәт!***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(6-7 яшь)***

## Хәрәкәтле уен «Бабай һәм оныклар».

Бер бала – бабай, калганнары – оныклар; бабай өйдә уты- ра, ә оныклар өйдән читтәрәк нәрсә эшләячәкләре турында сөйләшәләр. Мәсәлән: бакчада җир казыдык, оекбаш бәйләдек, кер юдык һ.б. Аннары бабай янына киләләр, бабай алардан: «Сез кайда булдыгыз?»- дип сорый. Балалар: «өйдә», «урманда», «бак-чада» һ.б. дип җавап бирәләр. Бабай: «Сез анда нишләдегез?»- ди. Балалар бергәләп бертөрле хәрәкәт белән нәрсә эшләгәннәрен күрсәтәләр. Бабай белергә тиеш. Дөрес җавап әйтелгәч, балалар йөгерәләр, бабай аларны куа. Беренче тотылган бала бабай була.

## *Яулык алыш уены*

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

Талым, талым, талчыбык,

Уртасында бал чыбык,

Ал яулык, гөл яулык,

Бир син миңа бер яулык, —

дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

## Мәкальләр

Картлар сүзен капчыкка сал, яшьләрнекен янчыкка сал.

Олының сүзен оекка кыстыр.

Картлар сүзен кар басмас.

Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.

### *Оекбаш*

Кыш көне салкын булса да,

Сарык йоны җылы була.

Һич туңмый минем аяк.

Бар бит тагын шунысы —

Җылыта аны дәү әни

Күчкән аңа дәү әнием

Бәйләп биргән йон оек.

Кулларының җылысы.

Рафис Корбан